СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«МИЧУРИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«МИЧУРИН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
**МУНИЦИПАЛЬ**
**БЕРӘМЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

2022 елның «17» марты № 3

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлеге Советының 2013 елның 29 ноябрендәге 21а номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин выл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 6 декабрендәге 408-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 476-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Мичурин авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Мичурин авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлеге Советының 2013 елның 29 ноябрендәге 21а номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин выл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**1 статьяны** түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:
«блокланган төзелеш йорты - башка торак йорт (башка торак йортлар) белән бер рәттә гомуми ян стенасы (гомуми як стеналары) белән блокланган һәм җир кишәрлегенә аерым чыгу урыны булган торак йорт.»;
**22 статьяның 2 өлешенең 6 абзацын** «,шул исәптән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 11 өлешендә күрсәтелгән очракта;» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мичурин авылы, Совет ур., 26 йорт-административ бина, Совет ур., 28 йорт-мәдәният йорты бинасы; Яңа Сережкино авылы, Үзәк ур., 9 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Мичурин авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Ә.Иванова